| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2022 г.Зеленодольск № 231

Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны, җәмәгатьчелек белән фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы , Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән (2021 елның 3 июнендәге 73 номерлы, 2021 елның 19 ноябрендәге 115 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, әлеге карарга кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны, җәмәгатьчелек белән фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның 2 өлешендәге 3 пунктында «, шулай ук Районның социаль-икътисадый үсеш стратегиясенә үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты» сүзләрен;

1.2. 6 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Гавами тыңлауларны билгеләү турында мәгълүмат, аларны уздыру вакытын һәм урынын күрсәтеп, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә Район Уставы нигезендә ,бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш, шул исәптән рәсми сайтта урнаштырылырга, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба - Бердәм портал) урнаштырылырга тиеш.

Район халкын хәбәр итү максатларында гавами тыңлауларны һәм муниципаль норматив хокукый акт проектын билгеләү турында Бердәм порталда урнаштыруны , Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органының шәхси кабинетын кулланып гавами тыңлауларны әзерләү һәм уздыру белән шөгыльләнүче җирле үзидарә органының вәкаләтле хезмәткәре тарафыннан, Бердәм порталның кире элемтә платформасының тиешле бүлегендә (алга таба - органның шәхси кабинеты) гавами тыңлауларны әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән срокта әзерләүне һәм үткәрүне башкаручы гамәлгә ашыра.»;

1.3. 7 статьясын түбәндәге эчтәлекле 3.1. өлеш белән тулыландырырга:

«3.1. Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлауга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча үз күрсәтмәләрен һәм тәкъдимнәрен шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә җибәрергә хокуклы.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр Район халкы тарафыннан, соң, Бердәм портал кулланып, авторизациядән соң «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификациянең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә кертелә.

Күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр кертү гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проектын һәм гавами тыңлауларны билгеләү турында мәгълүматны бастырып чыгару көненнән башлана һәм гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр кертелгәндә, Район халкы шулай ук үз фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), гражданның шәхесен таныклаучы төп документның реквизитлары, туу көне һәм яшәү урыны буенча теркәлү адресы турында белешмәләр җибәрә.

Күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр органның шәхси кабинетына җибәрелә.»;

1.4.9 статьяның 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр рәис һәм секретарь тарафыннан имзалана һәм кабул ителгән карарларның мотивлашкан нигезләнүен дә кертеп, Устав нигезендә, муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарыла (халыкка җиткерелә), шулай ук рәсми сайтта һәм федераль дәүләт мәгълүмат системасындагы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталында гавами тыңлаулар узган көннән алып, 5 көннән дә соңга калмыйча, эш көннәрендә исәпләнгән көндә урнаштырыла.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы

муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**